ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 июнь, 2017 ел № 17/6

Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 санлы Карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 3 апрелендәге «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатыннан Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 64-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 20 декабрендәге 22/13, 2015 елның 15 апрелендәге 39/15, 2016 елның 7 апрелендәге 7/7 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 маддәнең 5 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктны өстәргә:

«8) 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны һәм счетларга (кертемнәргә) ия булуны, акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) файдалануны тыю турында» 79-ФЗ санлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны башкармау»;

16 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 4.1 өлешен өстәргә:

«Контроль-хисап палатасы вазифаи затлары 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны һәм счетларга (кертемнәргә) ия булуны, акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) файдалануны тыю турында» 79-ФЗ санлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга мәҗбүр.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев